**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАДРЯКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАДРӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**423715,Республика Татарстан Мензелинский район, с.Кадряково, ул. Кирова, 31**

**423715, Татарстан Республикасы, Минзәлә районы, Кадрәк авылы, Киров урамы,31**

телефон: (85555) 2-61-24. E-mail: Kadr.Mnz@tatar.ru

Минзәлә муниципаль районының
Кадрәк авыл җирлеге Башкарма комитеты
Карары

от «27 » март 2020 ел №4

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының
Кадрәк авыл җирлеге гражданнарыннан үзара салым акчаларын җыю Тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасының “Җирле референдум турында”гы 23-ЗРТ номерлы Законы, Минзәлә муниципаль районы Кадрәк авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Кадрәк авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Кадрәк авыл җирлеге гражданнарыннан үзара салым акчаларын җыю Тәртибен расларга.
2. Әлеге карар рәсми төстә басылырга тиеш.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә йөклим.

Авыл җирлеге башлыгы Нәбиуллин Х.Х.

ТР Минзәлә муниципаль районы
Кадрәк авыл җирлеге
Башкарма комитеты
Карарына 1 нче кушымта
27 март 2020 ел. N 4

ТР Минзәлә муниципаль районы Кадрәк авыл жирлеге гражданнарыннан үзара салым акчаларын җыю Тәртибе

1. Әлеге Тәртип авыл җирлеге гражданнарыннан үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарга үзара салым акчаларын түләтү Бөек Ватан сугышында катнашучылардан һәм инвалидлардан, шулай ук 1 төркем инвалидлардан һәм көндезге формада укучы студентлардан тыш, 18 яше тулган, Минзәлә муниципаль районының Кадрэк авыл жирлеге территориясендә теркәлгән гражданнар тарафыннан, аларның җирле референдумда (гражданнар җыенында) катнашуына һәм тавыш бирүдә белдерелгән мөнәсәбәтенә бәйсез рәвештә, 31 мартка кадәр срокта башкарыла.

3. Җитди сәбәпләр булганда, аларга түбәндәгеләр керергә мөмкин:

а) авыру;

б) озакка сузылган командировка;

өч айдан артмаган срокка гариза нигезендә гражданнарга түләү кертү кичектерелергә мөмкин.

4. Бер тапкыр түләү турында хәбәр язуы (уведомление) бланкы Җирлекнең мәгълүмати стендында, Минзәлә муниципаль районы Кадрәк авыл җирлегенең menselinsk.tatarstan.ru рәсми сайтында бастыру, шулай ук имза куйдырып тапшыру яки почта элемтәсе аша җибәрү юлы белән гражданнарга җиткерелә.

5. Хәбәр язуында (уведомление) гражданнарның үзара салым акчаларын кертүгә түләү реквизитлары, тулысынча яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү күләме, аны түләү срогы күрсәтелергә тиеш (Кушымта).

6. Гражданнарның үзара салымнан кергән акчалата чаралары Минзәлә муниципаль районы Кадрәк авыл җирлегенең лицевой счетына керә.

7. Гражданнардан түләү алу почта (хисап оешмалары) переводларын башкаруга физик затларның йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясауга хокукы булган оешмалар, Минзәлә муниципаль районы Кадрәк авыл җирлеге Башкарма комитеты кассасы, https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша акчаларны күчерү юлы белән башкарыла.

8. Касса ордеры квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаучы башка документлар түләү фактын раслаучы булып тора.

9. Билгеләнгән срокта гражданнардан алынмаган үзара салым акчалары законда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

2 нче кушымта

ХӘБӘР ЯЗУЫ (УВЕДОМЛЕНИЕ) N ________________ Минзәлә муниципаль районы Кадрәк авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү кертү турында

түләүченең Ф.Ис.Ат.ис. ____________________________________________

Адресы: ____________________________________________

____________________________________________ нигезендә

Сезгә ____________ срокка кадәр ________________________ чараларны гамәлгә

____________________________________ ашыруга бер тапкыр түләү кертергә кирәк.

суммада ______________ сум, түбәндәге реквизитлар буенча: ________________

Түләү алучы банкның БИК ____________________________________________
Сч. N ____________________________________________
Кабул итүче Сч. N ____________________________________________
КПП ____________________________________________
КБК ______________ ОКАТО ________________
Түләү билгеләнеше ____________________________________________
Җитәкче ______________ ______________________________
М.У. (имза) (тулысынча имза)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү сызыгы - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

Хәбәр язуы (Уведомление) N ________________
Үзара салым буенча бюджетка бер тапкыр түләү кертү турында ____________________
____________________________________________
(муниципаль берәмлек атамасы)
суммада ________________ сум.

түләүченең Ф.Ис.Ат.ис. ____________________________________________
Адресы: ____________________________________________
Алдым "___" ________________ 20___ ел. ____________________________

________________________
(түләүченең имзасы)

Искәрмә. Хәбәр язуы төпсәсе (корешок) тутырыла һәм хәбәр язуы түләүченең шәхсән үзенә тапшырылган очракта, Башкарма комитетта кала.